| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| от 30.11.2016 | г. Казань | № 10-28/кс |

"2015 – 2017 елларга эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында" 2014 елның 5 декабрендәге 10-42/кс санлы Тарастан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә озак сроклы тарифларны 2017 елга үзгәртү турында

"Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, "Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәплэп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында" тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны билгеләү Реглмаентын раслау турында" 2014 елның 16 июлендәге 1154-э санлы тарифлар буенча Федераль хезмәт беорыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, һәм 2017-2018 елларга эчәргә яраклы суга һәм су бүлүгә озак сроклы тарифларны төзәтү максатыннан, 2017-2018 елларга җайга салынулы оешмаларның планлы кирәкле тулай табышын ачыклап Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "2015 – 2017 елларга эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында" 2014 елның 5 декабрендәге 10-42/кс санлы Тарастан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 кушымтаны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә яңа редакцияда бәян итергә;

2 кушымтаны әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

“Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының
2016 елның 30 ноябрендәге
10-28/кс санлы карарына кушымта
“Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының
2014 елның 5 декабрендәге 10-42/кс
санлы карарына 1 кушымта

2015 – 2017 елларга календарь чорларына бүлеп салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны башкаручы “Водоканал-Сервис” ҖЧҖе өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | | | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015ел | | 2016ел | | 2017ел | | 2015ел | | 2016ел | | 2017ел | |
| | | 01.01.2015 алып 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 алып 31.12.2015 кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2015 алып 30.06.2015 кадәр | 01.07.2015 алып 31.12.2015 кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр |
| | Арча муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | “Водоканал-Сервис”* ЖЧЖ | 33,32 | 34,80 | 34,80 | 37,19 | 36,62 | 36,62 | 38,00 | 38,72 | 38,72 | 42,10 | 34,97 | 34,97» |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

“Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
2016 елның 30 ноябрендәге
10-28/кс санлы карарына 2 кушымта
“Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитетының
2014 елның 5 декабрендәге 10-42/кс
санлы карарына 2 кушымта

2015 - 2017елы салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны башкаручы “Водоканал-Сервис” ҖЧҖе өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Табышларның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | “Водоканал-Сервис” ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчергә яраклы су | 2015 | 12023,21 | 1 | 0 | 4,39 | 2,18 |
| | | 2016 | 12507,31 | 1 | 0 | 4,39 | 2,18 |
| | | 2017 | 12927,89 | 1 | 0 | 4,4 | 2,18 |
| 1.2 | Су бүлү | 2015 | 8476,05 | 1 | 0 | - | 2,05 |
| | | 2016 | 8791,76 | 1 | 0 | - | 2,05 |
| | | 2017 | 9105,03 | 1 | 0 | - | 2,05» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
Дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге